**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**2021-2022 учебный год**
**10 класс**

**I. Һәр тотрыклы гыйбарәне синоним булырдай бер сыйфат белән алыштырып языгыз.** / Запишите каждый фразеологический оборот одним синонимичным прилагательным. (*10 баллов. За каждый правильный вариант по 1 баллу*).

1) Сүзе үтә торган – абруйлы, дәрәҗәле, ихтирамлы, авторитетлы, хөрмәтле, мактаулы, санлы, йогынтылы
2) шалкан бәясе – арзан, арзанлы, юнь, очсыз, бәясез
3) ике йөзле – аумакай, тотнаксыз, тотрыксыз, аумалы
4) ачык авыз – булдыксыз, уңмаган, булмаган, талантсыз, сәләтсез, җебегән, пешмәгән
5) салкын күңелле – гамьсез, ваемсыз, кайгысыз, хафасыз, кайгыртусыз, сансыз, борчусыз
6) җиңел сөякле – җитез, елдам, өлгер, елгыр, хәрәкәтчән
7) олы җанлы – игелекле, шәфкатьле, шәфәгатьле, ярдәмчел, хәерле,
8) кош теле хәтле – кечкенә, вак, бәләкәй, нәни, кече, кечек,
9) ачык йөзле – көләч, көлемсәр, елмаюлы,
10) балтасы суга төшкән – күңелсез, юанычсыз, сөенечсез, өметсез, кайгылы

**II. *Тура – урат, туар – утар, төс – сөт* мисалларында тел уйнату нәрсәгә нигезләнгән? Ул кайсы термин белән атала? Әлеге алымны кулланып, *мәл, кесә, ташы, тамак* сүзләренең парларын языгыз. Шундый ук тагын 2 мисал китерегез. /** На чём основана языковая игра в примерах *тура – урат, туар – утар, төс – сөт*? Каким термином она обозначается? Используя данный приём, запишите соответствующую пару для каждого слова: *мәл, кесә, ташы, тамак*. Приведите 2 аналогичных примера. (*10 баллов. 1 балл за объяснение сути приёма языковой игры; 1 балл за правильно указанный термин; по 1 баллу за каждое верно разгаданное слово и за объяснение значения; по 2 балла за каждый свой пример*).

1) Тел уйнату, сүз эчендәге хәрефләрнең урынын үзгәртеп, яңа сүз ясауга нигезләнгән.
2) Бу алым анаграмма дип атала.
3) **Мәл – ләм**
**Кесә – сәке**
**Ташы** – шыта
**Тамак** - макта
4) Шат – таш
Бөтен – төбен

**III. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз. /** Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении (10 баллов).

*Үз алдыңа куйган максатны тормышка ашыруга иртәгә тотынырмын дип уйлама.*

Үз – алмашлык, билгеләү алмашлыгы, тамыр алмашлык, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, баш килештә, җөмләдә аергыч.
Алдыңа – бәйлек сүз, исемләшкән, икенче зат берлектәге тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендә, җөмләдә хәл.
Куйган – сыйфат фигыль, тамыр нигез, төп юнәлештә, барлык формасында, үткән заманда, җөмләдә аергыч.

Максатны - исем, уртаклык исем, тамыр исем, төшем килешендә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, җөмләдә тәмамлык.
Тормышка - исем, уртаклык исем, ясалма исем, юнәлеш килешендә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, җөмләдә аергыч.
Ашыруга – фигыль, исем фигыль, затланышсыз, барлыкта, юнәлеш килешендә, җөмләдә тәмамлык.
Иртәгә – рәвеш, вакыт рәвеше, җөмләдә вакыт хәле.
Тотынырмын – хикәя фигыль, затланышлы, билгесез киләчәк заманда, берлек санда, 1 зат, җөмләдә максак хәле.
дип – ярдәмче фигыль, хәл фигыль формасында, барлыкта, җөмләдә максат хәле составында.
уйлама- фигыль, боерык фигыль, 2 затта, берлек санда, юклыкта, җөмләдә хәбәр.

**IV. Лингвистик терминнар һәм тел берәмлекләре арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапны сан – хәреф формасында языгыз.** / Установите соответствие между лингвистическими терминами и языковыми единицами. Ответ представьте в виде: цифра - буква. (10 баллов. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* )
1) Паронимнар; 2) синонимнар; 3) тарихи сүзләр; 4) архаизмнар; 5) омонимнар; 6) диалектизмнар; 7) алынма сүзләр; 8) антонимнар; 9) Күп мәгънәле сүзләр; 10) Бер мәгънәле сүзләр.
А) Каптыргыч, каптырма; Ә) Сүрән, сүлпән; Б) Мәктәп, шагыйрь; В) Капчык, каравыл; Г) Ызба, алҗапма; Д) Имана, чикмән; Е) Керем – чыгым; Ж) ошый – охшый, гыйбарәт – гыйбрәт; З) Яр, тиен; И) Гакыл, аяк.

**1 – Ж; 2 – Ә; 3 – Д; 4 – И; 5 – З; 6 – Г; 7 – Б; 8 – Е; 9 – В;10 - А**

**V. Русча гыйбарәләрнең татарча эквивалентларын языгыз.** / Напишите татарские эквиваленты, соответствующие выражениям на русском языке. (15 баллов. *За каждый правильный вариант по 3 балла*)
**Душа в пятки ушла –** кот очу, кот алыну
**Держать в ежовых рукавицах –** коры тоту
**Толочь воду (в ступе) –** корыны бушка аудару
**Кожа да кости –** коры сөяге генә калу, карга чукырлык ите калмаган
**Втирать очки** - күз буяу

**VI. Сүзләрнең берсе тамырының мәгънәсе белән башкаларыннан аерылып тора. Әлеге сүзне табыгыз һәм мәгънәсен языгыз. Шул тамырдан 2 яңа сүз уйлап языгыз.** / Одно из слов отличается от других значением корня. Запишите это слово и смысл. Из этого корня придумайте 2 новых слова. (*5 баллов. 3 балла за правильно указанное слово и смысл; по 1 баллу за каждое верно написанное слово*)
Бозгыч, бозым, бозык, бозлавык, бозылышу.

**бозлавык –** 1. Яңгыр яки юеш кардан соң кинәт суыту нәтиҗәсендә, җирне тоташ каплаган боз кабыгы, тайгаклык. 2. с. мәгъ. Бозланган, боз кабыгы белән капланган, тайгак.
Бозлы, бозлык

**VII. Татар телендә сүзнең лексик мәгънәсе турында ниләр беләсез? 1) бер мәгънәле һәм 2) күп мәгънәле сүзләр, 3) аларны сөйләмдә куллану турында языгыз; 4) мисаллар китерегез.** / Что Вы знаете о лексическом значении слова в татарском языке? Напишите об 1) однозначных и многозначных словах; 2) об их использовании в речи; 3) приведите примеры. *(15 баллов. Каждый критерий оценивается 5 баллами)*

Сүз дип үзенең эчтәлегендә мәгълүм төшенчә алган, реаль чынбарлыкның теге яки бу ягын чагылдырган, халык тарафыннан кабул ителгән авазлар системасы ярдәмендә мәгънә берлегенә ия булган, теге яки бу грамматик категориягә билгеле бер мөнәсәбәттә торган тел берәмлеген атыйлар.
Структур яктан бөтен булган сүз аерым **лексик мәгънәгә ия була**, ягъни һәр мәгънәдә чынбарлыкның бер өлеше чагыла, мәсәлән: өй – торак; түгәрәк – геометрик фигура. Һәр лексик берәмлек өчен бердәнбер, индивидуаль саналган лексик мәгънә чынбарлыкның билгеле бер күренешен генә чагылдыра. Өченчедән, сүз реаль тормыш, чынбарлыктагы әйбер, күренеш, процесс, билгеләрне атый һәм аларны лексик мәгънә кысаларында шушы телдә сөйләшүчеләргә җиткерә.
**Сүзнең лексик мәгънәсе ул** – сүзнең эчтәлеге, эчке табигате, сүздә чынбарлыкның теге яки бу күренеше (предмет (өстәл, кашык, тәрәзә), билге (ак, кара, сыек), эш-хәл (бару, уку, карау), мөнәсәбәт (ярату, ачулану һ.б.) чагылышы.
Телнең лексик системасындагы сүзләр ике төркемгә: **бер мәгънәле (моносемантик) һәм күп мәгънәле (полисемантик)** сүзләргә бүленәләр. Сүзнең бер генә мәгънәгә ия булу үзенчәлеге, икенче төрле әйткәндә, сүзнең билгеле бер авазлар җыелмасы белән бирелгән тотрыклы лексик мәгънә алуы б е р м ә г ъ н ә л е л е к яки м о н о с е м и я (грек. monos – бер + sema – билге) күренеше дип атала. Бермәгънәлелек семантик яктан берпланлылык белән характерлана. Бер мәгънәле сүзләрдә әйбер, күренеш белән аның атамасы арасында тәңгәллек, туры пропорция урын ала (сүз ↔ әйбер (күренеш)), ягъни сүз туры, конкрет мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән, измәче ‘измә.
**Бер мәгънәле сүзләргә**, нигездә, түбәндәгеләр керә: ялгызлык исемнәре; терминнар; неологизмнар
**Күп мәгънәле** дип (грек. polysemos – билгеләр күплеге) сүзнең бер-үк вакытта бер-берсе белән бәйле берничә мәгънәгә ия булу семантик үзенчәлеге атала.
Татар телендәге сүзләрнең абсолют күпчелеге – күп мәгънәле. Сүз мәгънәләренең берсе – төп (беренчел, номинатив) мәгънә, калганнары – шуңа бәйле өстәмә (икенчел) мәгънәләр.

**VIII. «Һиндларның «омара вазанги» дигән борынгы һәм изге гыйбарәсендә куәтле уңай энергия бар дип санала. Бу тәгъбир аларда акыл һәм тирән уй-фикер уята икән» дип язган Рашат Низами. Ә татар сүзләренең көче, энергиясе бармы? Сез ничек уйлыйсыз? Шуңа мөнәсәбәтегезне белдереп языгыз. Язмагыз 80 сүздән ким булмаска тиеш. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез. /** Считается, что индийцы имеют мощную положительную энергию в древнем и святом выражении «омара вазанги». Оказывается, эта формулировка вызывает у них глубокие мысли и размышления». Так пишет Рашат Низами. Как Вы думаете, есть ли сила, энергия татарских слов? Напишите сочинение-рассуждение (не менее 80 слов), выражая ваше отношение к этому. Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов)

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу** | |

| | | |
|---|---|---|
| | **эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |

| | |
|---|---|
| **Язма эш өчен максималь балл** | **20** |